■ Ә сез беләсезме?

# ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ

Бүгенге көндә кайсы диндә хатын-кызның хокуклары кимрәк дигән сорау куйсак, һичшиксез, күпчелек кеше ислам динендә дип әйтер иде. Моның сәбәбе ислам дине дошманнарының гасырдан артык мөселман хатыннарының хокуклары бозылуы турында чаң кагуларында. Ә без, кайчандыр көчле булган һәм алдынгы урында торган мөселманнар, бүгенге көндә шуларның ихтыярына буйсынабыз. Көчләп тагылган фикерләр белән эш итүебез аркасында Аллаһы Тәгалә биргән көч-кодрәтебезне югалттык та инде. Көндәлек тормышыбызда дин күрсәтмәләрен үтәмибез. Тормышыбыз, гаиләләребез Көнбатыш илләре үрнәгендә җайланган.

Ислам динен гаепләргә җыенган кеше башка халыклардагы һәм башка диннәрдәге хатын-кызларның тормышлары белән дә кызыксынып карасын иде. Византиядә дә, Персиядә дә, Индия белән Кытайда да, яһүдиләрдә һәм христианнарда да, ислам динен кабул иткәнче яшәгән гарәпләрдә дә хатын-кызларның хәле яхшылардан түгел иде. Тарих буенча китапларны укып карасагыз, хатын-кызларның бернинди хокуклары булмавын, аларның хайваннарга тиң булуларын, җаннары булмавын һ.б. күрерсез. Ислам дине килгәнче хатын-кызлар күпме кимсетелүләргә дучар булган!

Мәсәлән, ислам динен кабул иткәнче гарәпләр ярлылык һәм хурлыктан куркып, яңа туган кыз балаларын тере килеш күмгәннәр. Коръәни Кәримдә бу турыда болай диелә: "Әгәр ул мөшрикләрнең берсенә "кыз балаң туган", дип, сөенеч бирелсә, хатынына ачуланып, дусларыннан оялып, йөзе каралып китәдер. Кыз белән сөенеч бирелгәнлектән хурланып кауменнән качып, уйлап торадыр: бу кызны хурланып кына асрыйммы икән, яки терелэтә туфракка күмеп таптыйммы икән, дип. Әгаһ булсыннар, кылган эшләре нинди яман кабәхәт эштер!" (16:58-59).

Ислам дине килү белән хатын-кызларда хокуклар барлыкка килә. Аңа хөрмәт белән карый башлыйлар. Ислам динендә ана хокуклары ата кеше хокукларыннан өстенрәк була башлый. Моны Абу Хурайра китергән хәдис дәлилли. "Бер кеше Пәйгамбәрдән сорый: "Кешеләрдән кайсысы минем яхшырак мөгалләмә лаеграк?" Пәйгамбәр с.г.в. әйтте: "Синең әниең". Кеше сорады: "Ә аннары кем?". Кабат: "Синең әниең", - диде. Кеше сорады: Ә аннары кем?" Пәйгамбәр с.г.в. җавап бирде: "Синең әтиең".

Ислам дине килү белән "хатын-кыз" сүзе горурлык белән әйтелә башлады, чөнки бу сүз белән Коръәни Кәримдәге зур сүрәләрнең берсе атала. Аллаһы Тәгалә дине хатын-кызларга мирас калдыру хокукы бирә һәм шулай ук хатын-кыз милкен кагылгысыз итә.

Бу, ислам дине хатын-кызларга биргән хокукларның берничәсе генә.

Феминистик оешмалар хатын-кызларга азатлык бирүне таләп итәләр, ә без андый азатлыкның хатын-кызга зарар китерүен күрәбез, чөнки чиксез азатлык беркемгә дә яхшылык китерми. Ул азатлык азат хатын-кызларга нәрсә бирә соң? Тәннәре белән сату итүнеме? Хәмер эчемлекләр эчүнеме? Наркоманиянеме? Теләсә кем белән җенси мөнәсәбәтләргә керә алунымы? Нәрсәгә кирәк мондый азатлык? Кемгә кирәк мондый азатлык? Бу "азат" хатын-кызның матурлыгы кемгә кирәк? Ә картайгач ул үзе кемгә кирәк булачак? Ул картлык көннәрен ялгыз кичерә, балалары аның янына елга бер-ике мәртәбә килеп хәлен белә яки бөтенләй ташлыйлар.

Уйланыгыз! Бу хатын ислам дине биргән азатлык файдасын сайлап, уйдырма азатлыктан баш кага. Ул миллионнарча хатын-кыз таба алмаганны табуы белән бәхетле. Уйланыгыз һәм аның чакыруына колак салыгыз, хөрмәтле хатын-кызлар!

Ир-ат таш һәм кирпечтән йорт салса, бу йорт - бу дөньяның бәрәкәте, ә йортка турылыклы хатын-кыз тутырган ямь, җылылык һәм тәрбия бу һәм киләчәк дөнья өчен бәрәкәт булып тора.

Йорт - мосолман кешесенең ныгытмасы. Әгәр дә бу ныгытманы төзүдә хатын-кыз катнашмаса, анда бәрәкәт булмый. Аллаһы Тәгаләне зикер иткән, ислам динен өйрәнгән, турылыклы мөселманнар тәрбияләгән гаиләләр бәхетле.

Ана-батырларны, галимнәрне һәм тәкъва кешеләрне тәрбияләүче. Безне чын тормыш белән таныштыручылар - күркәм холыклы, дини, белүче, сабыр, дога кылучы, үкенүче әниләребез.

Мондый хатын-кызларның берсе белән пәйгамбәребез (с.г.в.) пәйгамбәр булганчы да, булгач та ризалыкта тигез тормыш кичергән. Хәдичә (г.с.) - ислам динен беренчеләрдән кабул итүче, пәйгамбәребез белән беренче намаз кылучы, беренче Җәннәт белән шатландырылучы, Коръәнне беренче ишетүче. Аны Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә аша сәламли. Ул үзенең милкен Аллаһы Тәгалә юлына тота. Пәйгамбәребезне кешеләр кире каккач та, ул аңа ышана, ялганда гаепләгәч - хаклыгын раслый, ярдәмсез калдыргач - ярдәм итә. Һәм Аллаһы Тәгалә аларны балалар белән шатландыра.

Пәйгамбәребезнең Хәдичәдән туган кызы Фатыйма, Хәсән белән Хөсәеннең әнисе, Гали хатыны - бөтен хатын-кыз һәм барлык аналар өчен үрнәк булып тора.

Гәйсә пәйгамбәр әнисе Мәрьямнең диндарлыгы хакында Коръәни Кәримнең күп кенә аятләрендә әйтелә. Аның исеме белән Коръәни Кәримнең сүрәсе атала.

Фиргәвен хатыны Асия дә, иренең ышанмавына карамастан, Аллаһы Тәгаләгә ышана. Ул Муса г.с. пәйгамбәрне тәрбияли.

Бөек галимнәр, укытучылар тормышын өйрәнсәк, аларның галим булуларында яшьтән үк белем алырга өндәгән әниләренең өлеше зур. Мисал итеп, Әбү Хәнифә, Имам Шафиины һ.б. китерергә була.

Уйланыгыз! Хатын-кызларга аеруча ихтирам күрсәтелә башлау ислам дине белән бәйле түгелме соң? Ирләре хатыннарын саклап кына торырдай энҗе бертеге дип атамыйлармы? Мондый хөрмәт Аллаһы Тәгаләгә буйсынган, Аның күрсәтмәләрен башкарган һәм тыйганарыннан баш тарткан хатын-кызларга гына насыйп була. Без, ир-атларда, дүрт хатын-кызга карата бурычларыбыз бар: әниебезгә, хәләл җефетебезгә, сеңелебезгә һәм кыз балабызга. Аллаһы Тәгалә бездән аларның һәрберсе турында сораячак. Без аларның хокукларын саклаганбызмы? Әниебезнең сүзен тыңлаганбызмы, аңа карата яхшы теләктә булганбызмы, шатландырырга тырышканбызмы? Сеңелебезне яклаганбызмы, хәләл җефетебезгә карата гадел булганбызмы, кыз балабызга дөрес тәрбия биргәнбезме?

Бөтен дөнья ел саен 8 март көнен - хатын-кызлар бәйрәмен билгеләп үтә. Бу бәйрәмнең килеп чыгышы турында төрле юрамалар йөри. Безнең өчен кадерле булган хатын-кызларыбызны елга бер тапкыр гына, уйлап чыгарылган бәйрәмне сәбәп итеп, игътибар күрсәтеп, үпкәләтәсе килми. Бу бәйрәмне оештыручыларга сәбәп кирәк булса, мөселман кешесенә хатын-кызларына һәркөн бәйрәм оештырырга кирәк. Әгәр дә без әдәпле һәм әниләребезгә карата ихтирамлы булсак, ярдәм итәргә һәм шатландырырга тырышсак, алар өчен бу бәйрәм түгелме соң? Сеңелебезгә шалтыратып, хәлләрен белешеп, кунакка барып йөрсәк, сеңлебез өчен бу бәйрәм булмыймы соң? Хатыныбызга карата гадел булсак, йомшак сүзләр кулланып сөйләшсәк, ягымлы һәм игътибарлы булсак, бу алар өчен бәйрәм булмыймы соң? Кызыбызны яхшы гореф-гадәтләрдә йомшак холыклы итеп тәрбияләсәк, бу аның өчен шатлык булмыймы соң?

Әйе, кардәшләр, бу чынлыкта да шулай. Әгәр дә без, ир-атлар, хатын-кызларыбызның һәрберсенә тиешлесен бирсәк, гаилә бәйләнешләре нык булачак, ә моның белән бергә без яшәгән җәмгыять тә күпкә яхшырачак.

Вәгаземне тәмамлап, сезгә Аллаһы Тәгалә сүзен исегезгә төшерәсем килә: "Ий кешеләр! Сезне бер ата-анадан яратучы Аллаһуга каршылык күрсәтүдән сакланыгыз, Ул Адәм г-мнең үзеннән хатын яратты вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһуга тәкъвалык кылыгыз ки үзегез. Ул - Аллаһ исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, шулай булгач, Аллаһуны зурлагыз вә якын кардәшләр хакыннан сакланыгыз! Бит Аллаһ сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче (Коръән. Ниса (хатыннар) сүрәсе, 1 аять).

**ГАБДУЛЛА**
**хәзрәт вәгазеннән.**

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Йомадиәл ахыр-Рәҗәб 2012 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Йомадиәл-ахыр, Рәҗәб | Аҙна көндәре | Апрель, Май | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Шишәмбе | 16 | 5-43 | 7.13 | 14.30 | 19.49 | 21.19 | 22.49 |
| 7 | Шаршамбы | 17 | 5.41 | 7.11 | 14.30 | 19.51 | 21.21 | 22.51 |
| 8 | Кесе йома | 18 | 5.38 | 7.08 | 14.30 | 19.53 | 21.23 | 22.53 |
| 9 | Йома | 19 | 5.36 | 7.06 | 14.30 | 19.55 | 21.25 | 22.55 |
| 10 | Шәмбе | 20 | 5.34 | 7.04 | 14.30 | 19.57 | 21.27 | 22.57 |
| 11 | Йәкшәмбе | 21 | 5.31 | 7.01 | 14.30 | 19.59 | 19.29 | 22.59 |
| 12 | Дүшәмбе | 22 | 5.29 | 6.59 | 14.30 | 20.01 | 21.31 | 23.01 |
| 13 | Шишәмбе | 23 | 5.27 | 6.57 | 14.30 | 20.03 | 21.33 | 23.03 |
| 14 | Шаршамбы | 24 | 5.24 | 6.54 | 14.30 | 20.05 | 21.35 | 23.05 |
| 15 | Кесе йома | 25 | 5.22 | 6.52 | 14.30 | 20.07 | 21.37 | 23.07 |
| 16 | Йома | 26 | 5.20 | 6.50 | 14.30 | 20.09 | 21.39 | 23.09 |
| 17 | Шәмбе | 27 | 5.18 | 6.48 | 14.30 | 20.11 | 21.41 | 23.11 |
| 18 | Йәкшәмбе | 28 | 5.15 | 6.45 | 14.30 | 20.12 | 21.42 | 23.12 |
| 19 | Дүшәмбе | 29 | 5.13 | 6.43 | 14.30 | 20.14 | 21.44 | 23.14 |
| 20 | Шишәмбе | 30 | 5.11 | 6.41 | 14.30 | 20.16 | 21.46 | 23.16 |
| 21 | Шаршамбы | 1 | 5.09 | 6.39 | 14.30 | 20.18 | 21.48 | 23.18 |
| 22 | Кесе йома | 2 | 5.07 | 6.37 | 14.30 | 20.20 | 21.50 | 23.20 |
| 23 | Йома | 3 | 5.05 | 6.35 | 14.30 | 20.22 | 21.52 | 23.22 |
| 24 | Шәмбе | 4 | 5.03 | 6.33 | 14.30 | 20.24 | 21.54 | 23.24 |
| 25 | Йәкшәмбе | 5 | 5.01 | 6.31 | 14.30 | 20.26 | 21.56 | 23.26 |
| 26 | Дүшәмбе | 6 | 4.59 | 6.29 | 14.30 | 20.28 | 21.58 | 23.28 |
| 27 | Шишәмбе | 7 | 4.57 | 6.27 | 14.30 | 20.29 | 21.59 | 23.29 |
| 28 | Шаршамбы | 8 | 4.55 | 6.25 | 14.30 | 20.31 | 22.01 | 23.31 |
| 29 | Кесе йома | 9 | 4.53 | 6.23 | 14.30 | 20.33 | 22.03 | 23.33 |
| 30 | Йома | 10 | 4.51 | 6.21 | 14.30 | 20.35 | 22.05 | 23.35 |
| 1 | Шәмбе | 11 | 4.49 | 6.19 | 14.30 | 20.37 | 22.07 | 23.37 |
| 2 | Йәкшәмбе | 12 | 4.47 | 6.17 | 14.30 | 20.38 | 22.08 | 23.38 |
| 3 | Дүшәмбе | 13 | 4.45 | 6.15 | 14.30 | 20.40 | 22.10 | 23.40 |
| 4 | Шишәмбе | 14 | 4.43 | 6.13 | 14.30 | 20.42 | 22.12 | 23.42 |
| 5 | Шаршамбы | 15 | 4.42 | 6.12 | 14.30 | 20.44 | 22.14 | 23.44 |

# ТӘҮБӘ ҺӘМ ИСТИЪФАР

Чыннан да без кешеләр Аллаһының җирендә тормыш итәбез. Аның кояшы астында назланабыз, ризыкларын ашыйбыз, татлы суларын эчәбез... Ул биргән күзләр белән карыйбыз, аяк-куллар белән хезмәт итәбез... Ул бүләк иткән балаларыбызны кочып куанабыз. Аның урманкырларында йөрибез, шифалы үләннәрен җыябыз, төрледән-төрле кош һәм хайваннары белән хозурланабыз... Әгәр кеше Раббысының аңа булган нигъмәтләрен санарга уйласа, беркайчан да санап бетерә алмас иде.

Әмма, ни кызганыч, Адәм баласы яши торгач, рәхәткә өйрәнеп китә, нигъмәтләрнең кадерен оныта, җир өстендә исраф кыла башлый. Иң аянычлысы - ул нигъмәтләрне бирүче Бөек Раббысын оныта. Аны искә алмый, шөкер итми... Ә бит Аллаһ ул нигъ-мәтләре өчен бездән һичбер мал-байлык сорамый. Бер генә шарт, кеше һәрвакыт рәхмәтле булырга тиеш: үстергән ата-анасына, укыткан остазына, күрше-дусларына, Ватанына, юктан бар итүче Раббысына... Әйе, бу нигъ-мәтләрнең дә бирүчесе онытыла, кеше үзен һичкемгә мохтаҗ түгел, һичкемгә бәйләнмәвен танырга тырышып, җир өстендә тәкәбберләнә башлый. Шул вакыт, Аллаһы Тәгалә кешене шушы явызлыктан туктау өчен, бәндәсен ул нигъмәтләрдән мәхрүм итә башлый. Шулай шул, югалтмыйча, күп нәрсәнең кадерен белә алмыйбыз. Башыбызга төшкән фәкыйрьлек - байлыкның, авыру - саулыкның, ялгызлык - якыннарның, картлык - яшьлекнең, әҗәл - гомернең, михнәт - рәхәтнең кадерен белергә өйрәтә.

Искә алынып киткән бәһасез нигъмәтләрнең берсенә генә тукталып, аның кыйммәтен исебезгә төшереп китәсебез килә... Ул да булса. Су нигъмәте. Әйе, гади су. Шиксез һәм тозсыз, итсез һәм майсыз су нигъмәте. Дөньяда тормыш итүче бер генә мәхлүк тә судан башка яши алмый. Алай гына да түгел, Аллаһы Тәгалә һәр тереклекнең башлангычын судан кылган. Чиста суларны эчеп сусавыбызны басабыз, тәнебезне кердән арындырабыз, киемнәребезне, тору урыннарыбызны пакьлыйбыз. Җиләк-җимешләр, яшелчәләр үстерәбез. Су һаваны сафландыра, елга-диңгезләр хәләл ризыкларын үстерә, энҗе-мәрҗәннәрен чыгара, корабларыбызны йөздерә...

Су - тереклекнең нигезе, әмма күбебез аның бәясен аңлап бетермибез. Үзебезгә: "Ул суларны җир асларыннан кем чыгарган, кем ерак җирләрдән болытларны куалап, шифалы яңгырларын яудырган?" - дигән сорауны бирмибез. Аллаһ Тәгалә әйтте:

"Эчкән суларыгызны күрәсезме? Сез аларны болыттан индерәсезме, әллә Безме? Әгәр теләсәк, аны эчә алмаслык ачы итәр идек, ни өчен сез шөкеритмисез?" (Вакыйга: 68-70). Әгәр Аллаһ теләмәсә, күкләр яңгырларын яудырыр идеме, җир буйлап елга-диңгезләр агар идеме, җир куеныннан салкын чишмә сулары бәреп чыгар идеме? Ни өчен шөкер итмибез, нигъмәтләрнең кадерен белмибез? Суны теләсә кайда агызабыз. Борынгылар агып торган елга суларын да саклык белән генә файдаланганнар. Әйе, Аллаһ рәхмәтсезлегебез сәбәпле нигъмәтләрен кисә. Нух пәйгамбәр вакытында туфан суында күк һәм җир сулары кушылган кебек, бүген дә күк сулары киселгәч елга-күлләр кими, чишмә-коелар кибә... Аллаһ Тәгалә әйтә:

"Уйлап карагызчы, әгәр җир асларыннан бәреп чыгучы чишмә сулары китеп юк булсалар, кем сезгә чиста сулар белән килер?" (Мөлек-30).

Һичкем килә алмас, Раббым. Син - галәмнәр Хуҗасы, көн белән төнне алыштыручы, ай һәм кояш белән идарә итүче. Син - рәхмәт җилләреңне җи-бәреп, болытларны куучы, җылы яңгырларыңны яудырып, корыган җирләрне терелтүче.

Яңгыр дигәне Аллаһ Тәгаләдән ике төрле була, берсе мәгънәви-рухый, икенчесе хисси, материаль яңгыр. Беренчесе кешенең калебендә иман һәм ныклык яңгыры булып ява, ул яңгыр җан азыгы, ике дөнья бәхете алып килә. Икенчесе күктән шифалы сулар булып төшә, үлгән, корыган җирләрне терелтә. Әмма беренче яңгырдан башка, икенче яңгырның буласы юк. Шуңа күрә кешенең кайбер гамәлләре сәбәпле күк капкалары ачыла, икенчеләре сәбәпле киресенчә, ябыла.

1. Тәүбә һәм истиъфар яңгыр яуның иң зур сәбәпләреннәндер.

Риваятьләрдә килгәнчә, мөэминнәр-нең әмире Гомәр ибн Хаттаб халкы белән истискага чыга, әмма догасында яңгыр турында бер сүз дә әйтми. Шулай да бөтен җирдә яңгыр ява...

Бервакыт, Хәсән әль Басри янына килеп бер кеше корылыкка зарланды, ул аңа: "Истигъфар кыл", - диде. Икенче берәү факыйрьлеккә зарланды, галим аңа: "Истигъфар кыл", - диде. Өченче кеше: "Минем өчен Аллаһыдан бала сорап дога кыл әле", - диде. Хәсән әль Басри аңа: "Истигъфар кыл", - диде. Дүртенче кеше бакчасы корудан зарлангач, аны да галим истигъфарга чакырды. Кешеләр бу хәлгә гаҗәпләнеп, аңа сорау бирделәр. Хәсән аларга: "Мин үзлегемнән һич нәрсә әйтмәдем, Аллаһ Тәгалә Нух сүрәсендә әйтте:

"Кешеләрнең кылган бозыклары сәбәпле җир һәм диңгез өсте бозылды. Моның белән Аллаһ кылган эшләренең бер өлешен кешеләрнең үзләренә татыта, бәлки шул вакыт алар бозыклыктан, изгелеккә кайтырлар" (Рум 41).

Гали ибн Әби Талиб: "Бәла гөнаһтан башка килмәс, тәүбәдән башка китмәс", - диде.

Газиз кардәшләрем, гөнаһларыбызны күрмәү, танымау, Аллаһка тиешле дәрәҗәдә тәүбә, истигъфар кылмау безнең бәлабездер. Борынгыларда шундый сүз булган: "Безнең тәүбәләребез, үзе тәүбәгә мохтаҗ".

2. Зәкят түләмәү күк капкаларын яба. Пәйгамбәребез: "Әгәр байлык малларының зәкятләрен тыйсалар, күктән явасы яңгырлардан да тыелырлар. Хайван-терлекләре дә булмаса, бөтенләй яңгырны күрмәсләр иде..." Ибн-Мәҗәһ.